ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 июня 2018 ел № 3721

Башкарма комитетның «2016, 2017, 2018 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын раслау турында» 2015 елның 25 декабрендәге 7414 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планын актуальләштерү максатында, Россия Федерациясе Торак кодексының 168 маддәсенең 7 бүлеге, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ санлы Законының 10 маддәсенең 11 бүлеге, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибен билгеләү турында» 2017 елның 20 мартындагы 155 нче карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/18 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.26 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2016, 2017, 2018 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь

ремонт үткәрү буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын раслау турында» 2015 елның 25 декабрендәге 7414 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 22 сентябрендәге 4903 нче карары редакциясендә) (алга таба – Кыска вакытлы муниципаль план) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне «Кыска вакытлы» сүзләреннән соң «муниципаль» сүзе белән тулыландырырга;

2) 1 пунктны «Кыска вакытлы» сүзләреннән соң «муниципаль» сүзе белән тулыландырырга;

3) карарга кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

4) Кыска вакытлы муниципаль планга 1, 2, 6, 7, 8 нче кушымталарны төшереп калдырырга;

5) Кыска вакытлы муниципаль планны әлеге карарга 2-10 нчы кушымталарда каралган редакциядә 1-9 нчы кушымталар белән тулыландырырга.

2. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә әлеге карарны торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 29 июнендәге
3721 нче карарына
1 нче кушымта

Башкарма комитетның
2015 елның 25 декабрендәге
7414 нче карарына
кушымта

2016, 2017, 2018 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2013 елның 31 декабрендәге 1146 нчы карары белән расланган
Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күп фатирлы йортларда
гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка
ашыруның кыска вакытлы муниципаль планы

1.Кыска вакытлы муниципаль планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп максатлары түбәндәгеләр:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге торак фондын саклау, торгызу һәм сыйфатын күтәрү;

2) гражданнарның куркынычсыз һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру;

3) күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү.

Кыска вакытлы планның төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) торак-коммуналь хуҗалыгы мәсьәләләре буенча халык белән актив агитация-аңлату эшләре үткәрү;

2) чыдам материаллар һәм ресурс саклау технологияләрен кулланып капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник карарлардан һәм комплекслылыктан файдалану.

2. Күп фатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләмнәре

Кыска вакытлы планны тормышка ашыру срогы: 2016-2018 еллар.

Әлеге Кыска вакытлы муниципаль планны тормышка ашыру гомуми мәйданы 5256494,92 квадрат метр булган 408 күп фатирлы йортта 201422 гражданның уңай һәм куркынычсыз яшәү шартларын тәэмин итүне күздә тота.

3. Күп фатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләме

| Т/с | Күп фатирлы йортта капиталь ремонт үткәрүнең эш төрләре | Үлчәү берәмлеге | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Күләме | Күләме | Күләме |
| 1 | Йорт эчендә җылылык белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | метр | 156111,4 | 103406,41 | 226947,4 |
| 2 | Йорт эчендә кайнар су белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | метр | 137169,67 | 104176 | 116187,4 |
| 3 | Йорт эчендә салкын су белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | метр | 69676,53 | 52762 | 65884,5 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Йорт эчендә су бирүнең инженерлык системасын ремонтлау | метр | 42032,9 | 36551 | 57559,5 |
| 5 | Йорт эчендә электр белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | кв.м. | 52407,7 | 15124 | 60085,7 |
| 6 | Исәпләү приборларын, җайга салу узелларын урнаштыру | данә | 8 | 22 | 0,00 |
| 7 | Подвалны ремонтлау | кв.м. | 9142,57 | 4284,4 | 0,00 |
| 8 | Түбәне ремонтлау | кв.м. | 55233,8 | 122783,2 | 48320,8 |
| 9 | Лифт җиһазларын ремонтлау/алмаштыру | данә | 61 | 48 | 90 |
| 10 | Фасадны ремонтлау | кв.м. | 151536,8 | 251742,6 | 275818,01 |
| 11 | Фасадны җылыту | кв.м. | 446 | 0,00 | 0,00 |
| 12 | Янгынга каршы автоматика һәм төтен бетерү системаларын урнаштыру | кв.м. | 20971,3 | 6000 | 18539,8 |
| 13 | Подъездларны ремонтлау | кв.м. | 92070,1 | 54314 | 15600,4 |
| 14 | Техник паспортлар ясау | данә | 150 | 99 | 92 |
| 15 | Фундаментны ныгыту | кв.м. | 11000 | 0,00 | 0,00 |

Кыска вакытлы муниципаль планга кертелгән ремонт төрләре буенча күп фатирлы йортлар реестры аңа 1-9 нчы кушымталарда күрсәтелгән.

## 3. Ресурс белән тәэмин итү

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, шәһәр бюджеты финанславы, торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативларының яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларының яисә күп фатирлы йорттагы торак милекчеләренең акчалары Кыска вакытлы муниципаль планны финанслау чыганаклары булып тора.

Кыска вакытлы муниципаль план чараларын финанслауның гомуми күләме 3 693 625 531,02 сумны тәшкил итәчәк, шул исәптән:

- Татарстан Республикасы бюджетыннан – 926 907 953,33 сум;
- шәһәр бюджетыннан – 802 041 000,00 сум;
- торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативлары әгъзаларыннан яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларыннан яисә күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләреннән – 1 964 676 577,69 сум.

| Финанслау чыганаклары | Финанс средстволары, барлыгы, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчалары | 329 564 653,30 | 293 690 550,03 | 303 652 750,00 |
| Шәһәр бюджеты акчалары | 267 347 000,00 | 267 347 000,00 | 267 347 000,00 |
| Торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативлары яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларыннан яисә күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләре акчалары | 566 334 314,82 | 559 519 296,23 | 838 822 966,64 |
| Барлыгы | 1 163 245 968,12 | 1 120 556 846,26 | 1 409 822 716,64 |

5. Күп фатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрүгә финанс средстволарының күләме

| Т/с | Күп фатирлы йортта капиталь ремонт үткәрүнең эш төрләре | Финанслауга ихтыяҗ, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
| 1 | Проект-смета документларын эшләү һәм экспертизалау | 9952479,53 | 11656610,14 | 19968031,21 |
| 2 | Техник күзәтчелек | 11330008,44 | 11614565,47 | 12994938,5 |
| 3 | Йорт эчендә җылылык белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | 266203706,51 | 172838474,14 | 305236088,99 |
| 4 | Йорт эчендә кайнар су белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | 199579861,36 | 137961677,54 | 150926256,49 |
| 5 | Йорт эчендә салкын су белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | 86086330,68 | 60738812,48 | 78411575,45 |
| 6 | Йорт эчендә су бирүнең инженерлык системасын ремонтлау | 67080651,85 | 57205995,24 | 102437825,55 |
| 7 | Йорт эчендә электр белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | 15116464,66 | 11387638,47 | 23522420,64 |
| 8 | Исәпләү приборларын, җайга салу узелларын урнаштыру | 7115663,92 | 12932996,82 | 0,00 |
| 9 | Подвалны ремонтлау | 4589065,81 | 4718477,93 | 0,00 |
| 10 | Түбәне ремонтлау | 75271597,79 | 167530819,33 | 79245468,26 |
| 11 | Лифт җиһазларын ремонтлау/алмаштыру | 110081153,64 | 96942094,43 | 197516414 |
| 12 | Фасадны ремонтлау | 223249813,26 | 342464668,96 | 410269123,9 |
| 13 | Фасадны җылыту | 4800000 | 0,00 | 0,00 |
| 14 | Янгынга каршы автоматика һәм төтен бетерү системаларын урнаштыру | 6560912 | 7871797,43 | 7650000 |
| 15 | Подъездларны ремонтлау | 38417528,65 | 16200978,7 | 10122390 |
| 16 | Фундаментны ныгыту | 29136657,18 | 0,00 | 0,00 |
| 17 | Техник паспортлар ясау | 8674072,84 | 8491239,18 | 11522183,65 |
| | Барлыгы | 1163245968,12 | 1120556846,26 | 1409822716,64 |

Капиталь ремонт үткәрүнең бәясе күрсәтелгән эш төрләре буенча күп фатирлы йортлар исемлеге Кыска вакытлы муниципаль планга 1-9 нчы кушымталарда күрсәтелгән.

6. Капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләрнең чик бәясе

2016-2018 елларга капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләрнең чик бәясенең күләме күп фатирлы йортлардагы бүлмәләрнең гомуми мәйданының 1 квадрат метры исәбеннән 14 мең сумны тәшкил итә.

Капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләрнең чик бәясен күтәрү, шулай ук Кыска вакытлы муниципаль планда каралмаган хезмәтләр һәм (яки) эшләр өчен түләү күп фатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең капиталь ремонтка минималь күләмдәге взносларыннан тыш, капиталь ремонтка взнос рәвешендә түләнә торган акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

## 7. Тормышка ашыру механизмы

Әлеге Кыска вакытлы муниципаль планны тормышка ашыру «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ (алга таба – Башкарма комитет), торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативлары, идарәче оешмалар, бүлмә милекчеләре, подрядчы оешмалар (алга таба – Кыска вакытлы муниципаль планны үтәүчеләр) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет:

1) Региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль (еллык) планын һәм Федераль закон нигезендә финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлешен раслый торган документларны формалаштыра һәм аларны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрә;

2) Министрлыкка норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм финанс ярдәме күрсәтү шартларының муниципаль берәмлек тарафыннан үтәлешен раслаучы башка документларны җибәрә;

3) КС-2 формасы буенча башкарылган эш актларын килештерә;

4) торак законнары нигезендә, 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм әлеге Кыска вакытлы муниципаль планда билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт буенча эшләрне финанслауга шәһәр бюджеты акчаларын күчерә;

5) капиталь ремонт буенча эшләрне кабул итү актын килештерә, күп фатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча расланган чыгымнар сметасында каралмаган акчалардан файдалану очракларыннан тыш, шулай ук аны күтәргән очракта;

6) күп фатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрүгә бирелгән акчаларның максатчан файдаланылуына контрольне гамәлгә ашыра;

7) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча Кыска вакытлы муниципаль планны тормышка ашыру максатында Министрлык билгеләгән тәртиптә мәгълүматлар базасын булдыра һәм аның актуаль торышын тәэмин итә;

8) Фондка хисаплар формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны Министрлыкка җибәрә.

Торак милекчеләре ширкәтләре, торак төзелеше кооперативлары, торак кооперативлары, идарәче оешмаларга түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1) тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефект ведомостьларын килештерергә;

2) дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алып проект документларын әзерләүне тәэмин итәргә;

3) капиталь ремонт объектларына керә алуны гамәлгә ашырырга;

4) күп фатирлы йортларда капиталь ремонтны үз вакытында һәм сыйфатлы башкаруга контрольне гамәлгә ашыруда, шулай ук аларны файдалануга кабул итүдә тикшерү актларын, һәм капиталь ремонт тәмамланган объектларны файдалануга кертү актларын имзалау хокукы белән катнашырга.

Торак милекчеләренә түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1) тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефект ведомостьларын килештерергә;

2) күп фатирлы йортларда капиталь ремонтны үз вакытында һәм сыйфатлы башкаруга контрольне гамәлгә ашыруда, шулай ук аларны файдалануга кабул итүдә тикшерү актларын, һәм капиталь ремонт тәмамланган объектларны файдалануга кертү актларын имзалау хокукы белән катнашырга.

Подрядчы оешмаларга түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1) күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча эшләр башкаруны подряд килешүендә билгеләнгән срокларда тәэмин итәргә;

2) КС-2, КС-3 формалары буенча башкарылган эш актларын формалаштырырга;

3) подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкарырга.

Кыска вакытлы муниципаль планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «Торак фонды мониторингы» мәгълүмати аналитик системасында гамәлгә ашырыла.

## 8. Күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкаруга подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе

Капиталь ремонт буенча эшләр башкару өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе Россия Федерациясенең «Күп фатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкаруга подрядчы оешмаларны җәлеп итү тәртибе һәм күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма фунцияләрен үтәү максатында товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2016 елның 1 июлендәге 615 нче Карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова